**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**Күзкәй авыл җирлеге составына керүче**
**Яңа Байлар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

# КАРАР

08 ноябрь 2025 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында 2019 елның 05 ноябрендәге 10/1 номерлы карары нигезендә 2025 елның 08 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Күзкәй авыл җирлегенең Яңа Байлар авылы территориясендә 2026 елда балигъ булган, Күзкәй авыл җирлегенең Яңа Байлар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә, I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә, аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Байлар авылында Октябрь урамы буенча балалар мәйданчыгы өчен җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру)

«ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы <u>**110**</u> кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 58 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 58 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Яңа Байлар авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «Күзкәй авыл җирлегенең Яңа Байлар авылы территориясендә 2026 елда балигъ булган, Күзкәй авыл җирлегенең Яңа Байлар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү

кертергә, I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә, аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Байлар авылында Октябрь урамы буенча балалар мәйданчыгы өчен җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру)» мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Яңа Байлар авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Яңа Байлар авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күзкәй авыл җирлеге Башлыгы — Э.Р. Гәрәев